**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Кариле авылы торак пунктында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**19 ноябрь 2023 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Кариле авылы торак пунктында халык җыены **карар бирде**:

1. 90% күләмендә ташлама каралган I нче төркем инвалидларын, Бөек Ватан сугышы ветераннарын, Бөек Ватан сугышы тол хатыннарын, тыл хезмәтчәннәрен, 80 яшьтән узган өлкәннәрне, 70 яшьтән узган балалары булмаган ялгыз яшәүче өлкәннәрне, Россия Федерациясе кораллы көчләрендә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларын, Россия Федерациясе кораллы көчләрендә контракт буенча хезмәт итүче гражданнарны исәпкә алмаганда, Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Кариле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнарга 2024 нче елда үзарасалымны 1000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- юл-урам челтәрен һәм юлларның асфальт-бетон капламын норматив хәлгә китерү;

- Г.Әшрәфҗанов урамы 5 нче һәм 7 нче күпфатирлы йотларның коймаларын төзекләндерү;

- балалар мәйданчыгы төзү һәм балалар спорт һәм уен җиһазлары сатып алу;

- Кариле авылында агач кисү, киселгән агачларны каты көнкүреш калдыклары полигоны чүп-чар җыю урынына илтү, территорияне чистарту һәм җыештыру.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Норма авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы мунципаль берәмлекләре порталы составындагы baltasi.tatarstan.ru. Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы

Шарипҗанов Р.Н.